9. Исхаки Г.Г. Поэт Габдулла Тукаев // Татарстан. – 1998. - №2. – С. 7-12.
10. Купрелезадэ М.Ф. Габдулла Тукаев // Огни Казани. – 2009. - №4. – С. 115-134. (Йолдыз ... Шура ... Тәрек йорты. – 1913. – 13 май.)
11. Мухамадиев Р.С. Еще раз о «Татарских поэтах» // Огни Казани. – 1987. - №3. – С.25-33.
12. Нуруллин И.З. Татарская литература начала XX века. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. – 228 с.
13. Современники о Тукае: Сборник воспоминаний, статей и литературных произведений. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1960. – 294 с.
14. Слово о Тукае: Писатели и ученые о татарском народном поэте. – Казань: Татар. кн. изд-во,1986. - 431 с.
15. Тукай и культура XX века. Материалы международной конференции, посвященной 110-летию поэта. Сборник статей. – Казань, 1997. – 322 с.
16. Уйгур. Новые произведения. «Татарские поэты» // Йулдуз. – 1913. – 4 августа.
17. Усманов Х. Татарская поэзия в период Великой Октябрьской революции и гражданской войны. – Казань: Изд-во Казанского университета, 1960. – 181 с.
18. Фахретдин Р.Ф. Новые произведения // Вакыт. – 1906. – 9 декабря.
19. Фахретдин Р.Ф. Мусамара (Звезды Востока и Запада) // Шура. – 1914. - №22. – С.701-704.
20. Халитов Г.М. С любовью к человеку и правде: Литературно-критические статьи. – Казань: Татар. кн. изд-во,1975. – 328 с.

## XX йөз ахыры татар балалар прозасында автор карашы белдерелеше

***Г.Р.Гайнуллина,***
*к.ф.н., доцент*
*Россия, Казань*

“Гомум әдәбият белән бергә, балалар әдәбияты да үзенең формалашуыннан башлап бүгенге көнгә кадәр катлаулы озын юл уза, кешелек тәҗрибәсендә булган матур традицияләргә таянып, дәвер таләпләренә җавап бирә торган үзгәрешләр кичерә, һәр чорда тәрбия өлкәсендәге әһәмиятле мәсьәләләрне яктыртып килә” [4, 3]. XX гасыр балалар әдәбиятының үзенчәлекләрен һәм үсеш тенденцияләрен махсус гыйльми хезмәтләрендә өйрәнгән әдәбият галиме Л.И.Минһаҗева фикеренчә, татар балалар әдәбияты XX йөз башында формалаша һәм төрле юнәлешләр белән үсеш ала [4, 6].

Балалар прозасында автор карашы белдерелеше дигән нәзари тема аерым фәнни эзләнүләр өлкәсе булып тора аламы? Безнең максат – Г.Гыйльман, Н.Гыйматдинованың аерым әсәрләренә шул ноктадан бәя биреп, бу мәсьәләнең мөһимлеген раслау.

XX гасырның 80 нче елларына татар прозасындагы стиль тенденцияләренең иң көчлесе – психологизм [3, 4]. Мәгълүм ки, XX йөз ахырында Г.Гыйльман, Н.Гыйматдинова һ.б. элгәргеләрдән Ф.Әмирханнар, Ш. Камаллар башлаган традицияне дәвам итеп, кешенең рухи дөньясын, психологиясен сурәтләү объекты дәрәҗәсенә күтәрәләр. Автор карашын белдерү юллары да төрләнә.

Г.Гыйльманның “Язмышның туган көне” хикәясендә ислам диненнән мәгълүм детальләрне, *әдәби мотивларны уйнату* бала күңелендә әдәплелек, матурлык тойгысын уятып, ныгытып куюның бер юлы, дип белдерелә.

Сугыш фаҗигасе балага ятимлек фаҗигасе алып килә. Хикәядә Зөһрә исемле кызның Язмыш белән “сөйләшүе” бер яктан ятим кызның күңелендәге уй-тойгыларны әйтеп бирү юлы булса, икенчедән, аның кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне аңлауда үткән беренче

сынавы. Хикәяләү Зөһрәнең уйларын тергезү рәвешендә алып барыла, димәк, әсәрдә куелган проблемаларның да аталышы аның *эчке сөйләмен*ә салына: “Зөһрәнең әтисе юк. Әнисе белән генә яши ул... Зөһрә белә: әтисез кеше булмый. Аның да әтисе бар. Әмма ул аларга бервакытта да килми” [1, 368]. *Кичерешләр чылбыры* ятимлек ачысы белән килешә алмаган кызның эчке сөйләменә салынган *трагик пафос* белән белән тасвирлана.

Героиняның эчке сөйләмендә рухи тормыштагы иң нәзек бәйләнешләр үзара тоташа, ул ихтыярсыздан үз заманы проблемаларын бәяләүчегә әверелә: “Зөһрә үзе дә әнисен рәнҗетмәскә, үпкәләтмәскә тырыша. Чөнки әнисенә болай да кыен. Ул бит кызын үзе генә, ялгызы үстерә... Беренче сентябрь көнне Зөһрәне мәктәпкә әнисе илтте. Соңрак санап карады: сыйныфтагы егерме дүрт баланың унбере әтисез” [1: 368]. Ятимлек ачысы татырга мәҗбүр ителгәннәр проблемасы иҗтимагый мотивлаша.

“Эчке сөйләмнең реаль психологик күңел хәрәкәте закончалыкларына буйсынуы, герой уйларын турыдан-туры тергезүгә” [2, 77] нигезләнгән булуы Зөһрәнең күңелендә барган бәрелешләрнең котелгән, алдагы кичерешләр белән әзерләнгән булуын укырга мөмкинлек бирә: “Бөтенесенә дә шул Язмыш гаепле, ахры. Үзләреннән башка гына кешеләрнең яшәвен, тормышын, бәхетен-бәхетсезлеген хәл итә торган бер көч бугай ул. Менә шул көч белән дуслашсаң иде дә...” [1, 369]. Димәк, бала күңеле *чарасызлыктан* чыгу юлын эзли башлый. Күренгәнчә, биредә ул үзен чолгап алган чынбарлыкның кануннарын кабул итә, өлкәннәр тәҗрибәсенә таяна.

Вакыйгалар Гүзәлия белән Зөһрә йортына “чит кеше” килеп керү ноктасында төенләнә. Бала күңелендә бөреләнгән яңа хис – *ихтыярсыздан билгесез көчкә ышану һәм аны чынбарлыктан эзләп табарга теләү тойгысы* кызны уяу булырга чакыра. Чит кеше белән әнисе сөйләшүен Зөһрә үзенчә шәрехли, аңарда үзен оныттылар дип *үпкәләү* тойгысы бик табигый туа.

Автор кызның эчке сөйләм структурасына хилафлык китермичә, үз карашын, фикерен өлкәннәр сүзе кебек урнаштыра. Зөһрә ишетүендә бирелгән Гүзәлия - Ясир сөйләшүе текстның сюжет калыбын алдан укырга мөмкинлек бирә:

– Язмыш очраштырды безне, Гүзәлия. Син – минем Язмышым бүләге...

– Бергә булу өчен Язмышны син генә түгел, мин дә тоярга тиеш, Ясир. Син беләсеңме шуны?.. Безнең Язмыш Зөһрә кулында, Ясир... Ул сине Язмыш бүләге итеп, хәтта Язмышның үзе итеп кабул итәргә тиеш. Язмыштан ул сине көтеп, сорап алсын иде” [1, 375].

Автор кеше үз тормышында булган һәр вакыйганы бүләк дип кабул иткәнче акыл-хис бәрелешен кичерә, ди. Һәр вакыйганы нигезли, аңлата, сәбәбен күрә башлагач, көрәш юкка чыга, кеше күңел тынычлыгына ирешә, дип тамырлары белән исламга тоташучы фәлсәфәне шәрехли. Акыл камилләшүгә омтылу булса, хис әлеге камиллекнең эчтәлеген мәхәббәт, үз тормышыңны ярата белү дип аңлата. Димәк, хикәядә кызның кичерешләр чылбыры үзенең тормышын бүләк дип кабул иткәнчегә кадәрле үстереләчәге көн кебек ачык.

Зөһрә күңелендә барлыкка килгән яңа тормышның билгесезлегеннән *курку, сагаю хисе* шәхси үсеш юлында һәркемгә хас булган хис буларак укыла: “Сагаерсың, куркырсың да шул... Моңа кадәрле тату, тыныч тормышлары җимерелсә? Зөһрә бик-бик бәхетсез булыр иде. Ул бәхетсез булгач, аның әнисе дә бәхетсез булыр иде...” [1, 378]. Кеше күнегелгән, гадәтигә әверелгән, җан тынычлыгыннан мәхрүм ителгән булса да, инде башкача булырга мөмкин түгеллеге расланган иске тормышын *югалтудан курка*, асылда аны яңа тормышның *билгесезлеге борчый*, күңелендә тирән урнашкан әлеге *курку* алда торган яңа юл турында җитди уйларга, аны нигезләргә, *сагынып көтеп алырга* комачаулый. Күңелендә туган бәрелешнең эчтәлеге курку хисе белән бәйле: “Тик... Нигә китерәсе килми соң аның бу абыйны? Нәрсәдән курка Зөһрә, нидә шикләнә, сагая?” [1, 378].

Кичерешләр чылбырында алдагы хисне рухи үсеш дәрәҗәсе әлегә акыл-хис бәрелешендә булган кешедә табигый булган башкалардан өстен булу тойгысын тудырган “видик” вакыйгасы билгели. Рәсим өйдә видик, компьютер булуы белән мактанганда, Рөстәм әтисенең тимер шкафтагы акчасы белән шапырынганда, “Зөһрәнең дә *мактанасы килде*” [1, 379]. Кыз үзенең мактанырлык байлыгы булмавын аңлагач, аклану өчен сәбәпне эзләп

тормый: “Их, әтисе яннарында булса, алар да бай булырлар иде” [1, 379]. Хәзер исә әтисенең “функциясе” үзгәрә: ул – байлык чыганагы. Димәк, кеше үзен канәгатьләндерә алмаган ситуациядә башкаларны гаепләүчән. Биредә кызның әнисе, күрше Салисә әбисе йогынтысында формалашкан матур эчке дөньясы баш калкытып ала, тик яшәп килүче җәмгыятькә бу актуаль яңгырамый, шуңа күрә Зөһрә тарафыннан яклау тапмый: “Урамда очратканда, Салисә әби Зөһрәнең аркасыннан сөеп: “Алтын шул синең әниең. Әнә ничек матур итеп карап, тәрбияләп йөртә...”, – дип әйтә торган иде. “Без дә бай! Беләсегез килсә, минем әнием алтын! – дигәнен сизми дә калды Зөһрә. Байлык хакындагы бәхәс шуның белән тукталды.Зөһрәнең байлыгы белән ярышып мактаныр бала табылмады” [1, 379]. Күренгәнчә, автор бала күңелендә туган гап-гади кичерешне иҗтимагый проблема дәрәҗәсенә күтәрә: җәмгыятьтә байлык матур эчке дөнья, әдәп, югары әхлак белән түгел, ә тышкы бизәк, акчага корылган яңа әхлак белән билгеләнә икән.

Кызда әнисе белән икесе өчен туган *гарьлек* хисе – аны Язмыш белән сөйләшүгә этәргән чик.

Ислам фәлсәфәсендәге Язмыш категориясенең балалар прозасына үтеп керүе яңа дулкын, күтәрелеш турында хәбәр итә. Бу турыда уйлануларны дөрес юнәлешкә борып җибәрү, язмышны кылган гамәлләрнең нәтиҗәсе кебек аңлату, асылда һәркемнең үз тормышы өчен җаваплы булырга тиешлеге турындагы хакыйкатьне алга чыгару – әдипнең матур табышы, уңышы да. Ясир-Язмыш хатлары автор позициясе кебек укыла, текстның соңында әдип моны раслап куюны кирәк таба.

Беренче хат кызның кичерешләр чылбырын билгесезлек белән очрашудан туган *гаҗәпләнү*, шул ук вакытта *ихластан ышану* дулкынына көйли. Кыз хатта үзе эзләгән җылылыкны таба, әнисе өйрәткән әдәпнең дәвамын укый, шуңа күрә сөенеп, яратып кабул итә, ышана: “Шуны бел: асыл байлык акчада да, алтында да, башка җибәрдә дә түгел. Кешенең байлыгы – саф, ихлас күңелендә, тугры җанында, ярсу йөрәгендә һәм матур хыялында” [1, 380]. Кеше икеләнү-борчылулар вакытында таяныч таба алса, үзен тулы канлы, бәхетле тоя. Әдип таяныч ноктасы кешенең үзендә, үз әхлагы белән билгеләнгән булырга тиеш дигән канунга китергәнче, аны Язмыш белән сөйләштерәчәк. Кыз шулкадәр бәхетле ки, ул күңелендә йөрткән Ясир абыйсына карата булган ачуны җуя (ул биргән сәгатьне тагып куя, күңелендә аның усал сурәтен матур елмаю белән алыштыра). Димәк, рухи күтәрелешнең беренче баскычы – башкаларга карата булган ачу хисен җую, аларның сурәтен үзгәртү, ди автор.

Бәхетле кеше тормышын үзгәртергә, матурайтырга омтыла. Кыз да Язмыштан зәңгәр чәчәкле гөл сорарга уйлавы – эчке дөньясын тагын да якты, камил итәргә омтылышыннан ул. Бөтен дөньяны балкытып торучы гөл кызның күңел халәте, рухи күтәрелеше билгесе.

Хисап фәненнән икеле алу вакыйгасында да төпле киңәше белән ярдәм кулын сузган Язмыш кызда үз-үзенә ышаныч тудыра, аны рухландыра, кыз икенче көнне ике “бишле” алып кайта. Димәк, иң мөһиме үзеңне кулга алу, беркайчан да үз көчеңә ышанычны җуймау, эзлекле булу. Руслан белән бәйле вакыйгада кызның авырлыкларга, физик һәм рухи кимсетүләргә каршы тора алуы сынала. Автор тормышта иң якын кешесеннән кимсетелүгә дучар ителгән бик күпләргә сабыр итәргә киңәш бирә, явызлыкны башкача җиңеп булмау турында әйтә. Кыз Русландагы олы йөрәкне шулай ышаныч белдереп ача. Димәк, рухи күтәрелешнең алдагы баскычы – башкаларга ышаныч белән карау, аларга юл сайлау мөмкинлеге калдыру.

Әлеге вакыйгалар кызны яңа үсеш баскычына – дога өйрәнүгә әзерли. Текстка кертелгән дога эчтәлекләре аерым катлам булып оеша. Автор аларны Зөһрәдән укыттыра, бала күңеленә илаһи көч турында, аның серле хакыйкать булуы хакында фикер сала. Бала Язмыштан алган киңәш- бүләкләрдән – тәрбиядән соң бу серле-тылсымлы көчкә тулаем ышана, таяна башлый. Димәк, автор баланы бу халәткә башкаларга карата ачу хисен җуйганнан соң, авыр хәлләрдән үз көчеңә, сабырлыгыңа таянып чыгарга өйрәнгәннән соң китерә. Кеше үзендәге илаһилыкны тормыш сынауларын дөрес үтсә генә таба, ди автор.Әгәр

сынаулар аша үтеп, үзенә тиешле тәрбия кыла алмаса, кеше илаһилыкка килә алмый, сына юкка чыга.

Әсәрдә алдагы вакыйганың кызның яшәү-үлем арасында калуы кебек оештырылуы очраклы түгел. Кыз буранлы төндә исән калуы белән гел Ясир абыйсына бурычлы кебек тоелса да, чынбарлыкта кызны илаһи көчкә һәм *үз-үзенә ышанычы* коткара. Биредә кызның халәтен аңлату өчен *төш алымы* кулланыла. Төш, билгеле булганча, психологик сурәтләүнең әһәмиятле алымы булып тора: "Бераздан ул үзенең сихри төш шаукымында калуын тойды. Аңа рәхәт тә, кыен да иде, ул бер үк вакытта бәхетле дә, бәхетсез дә иде. Чын, ихлас язмышлы һәрбер кеше кебек..." [1, 398]

Кичерешләр чылбырындагы эзлеклелек Зөһрә аңындагы каршылыкларның тигезләшүенә китерә: акыл яки хис кенә була алмый. Алдагы вакыйгаларның автор тарафыннан санап кителүе, ә кичерешләрнең яңармавы шул хакыйкатьне раслый. Яңа ел бәйрәме, чаңгылы булу вакыйгалары, ялганның бәхетсезлеккә китерүе турындагы хат – болар башка рухлы кызның уянуы турында хәбәр итә.

Туган көнгә Ясир-Язмышның килүе – кичерешләр сызыгында чишелеш. Чәчәкләр артына яшеренгән чибәр, акыллы, шаян, әйбәт Язмыш Зөһрә кебек матур рухлыларга бүләк ителә, ди автор. Героиня күңелендәге капма-каршы башлангычлар – акыл һәм хис, уяныш килүче шәхес омтылышлары бәрелеше хәл ителеш таба.

Әдип таяныч ноктасы кешенең үзендә, үз әхлагы белән билгеләнгән булырга тиеш дигән канунга китергәнче, аны Язмыш белән сөйләштерәчәк, дигән фикерне раслау соралып тора. Биредә "Соңгы сүз" бүлекчәсе очраклы түгел: "Менә шулай матур тәмамланды бу тарих. Тәмамланды микән? Бәлки, олы, бәхетле тарихның башы гынадыр бу?" [1, 411]. Димәк, үзенең бәхетле булып туган язмышы өчен кеше үзе җаваплы. Бу – авторның соңгы сүзе – карашы кебек укыла.

Н.Гыйматдинова да балаларга атап язган хикәя-повестьларында автор карашын психологизм алымнары белән аңлата, мифопоэтик структурага урнаштыра. Н.Гыйматдинованың "Болын патшасы" хикәясендә әдибәнең иҗатына хас булган мифологик мотивлар психологизм алымнары белән параллель гәүдәләнеш таба. Аяклары авырткан Рәсимне коткарган Айсылу исемле урман кызы Нәбирә Гыйматдинованың Акчәче, Сәвиләсе, Хаятенең кабатланышы кебек кабул ителә. Рәсим дә үз чиратында Рыскол, Тәминдар, Рөстәмнәрне кабатлый, кызны яклап өлкәннәр дөньясына каршы чыга. Тылсымлы чишмә көче, җил гайрәте малайга ярдәм итә алырлык табигать көчләре икәнлеген раслаган сюжет сызыгы әлеге иҗатка гашыйк укучыга яңалык алып килми кебек. Әлеге мотивларның балалар прозасында яңгыравы да Ф.Яруллин, Г.Сабитовның балаларга атап язылган хикәяләренә тоташа. Икенче яктан, автор укучысын Айсылу кичерешләренә гашыйк итеп, ышандырып яулый. Хикәядә мифологик катлам белән ярымреалистик, ярымромантик катлам аерымлана. Реалистик һәм романтик катламнар кушылмасындагы вакыйгалар барышында Рәсимнең кичерешләре ямьсез, сәер Айсылуны дөньядагы иң матур кыз итеп яратуга кадәр үстерелә. Мифологик катламда болын патшасы мотивы уйнатыла. Нәтиҗәдә Н.Гыйматдинова табигатьтән ерагаю кешене үз асылыннан алып китә, аны явыз, хиссез, төссез итә дигән караш үткәрә.

"Урман ниләр сөйли икән?" хикәясендә урман пространствосы диңгез белән чагыштырыла, янәшә куела. Вакыйгалар боланны үтерү ноктасында төенләнә, дүрт дусның берсенең этисе гаепле икәнлеген ачыклау белән чишелә. Урман диңгезе белән сөйләшү кебек каймаланган вакыйгалар баланың үз җаны, вөҗданы белән сөйләшүенә ишарәли. Наилнең үз этисе өчен борчыла белүе, вакыйганы дөрес бәяли, кичерә алуы авторның фикерен беркетеп куя. Өлкәннәр дә ялгыша, тик бу ялгышларны кабатларга ярамый, ди кебек әдибә.

Н.Гыйматдинова хикәя-повестьларында уйнатылган болан әкияти образы еш кына матур, тирән, әмма боек карашлы болан-табигатьнең кешеләргә уяу булырга кушып эндәшүе кебек аңлана. Диңгез – күңел дөньясының чагылышы булса, урман, болын бу җиһанга син алып килгән яктылык, матурлык пространствосы. Балалар өчен язылган хикәяләрендә

Гыйматдинова кеше үз хисләр диңгезенә хуҗа була алса гына, кешелек урманын, болынны ...та, ямьләндерә, аның патшасы була ала, ди.

XX йөз ахыры балалар прозасында Г.Гыйльман, Н.Гыйматдинова башлаган автор ...нын мифопоэтик структурага урнаштыру юнәлеше хәзерге татар балалар прозасында Г.Гаффарова, Р.Галиуллин һ.б. яшь прозаикларда дәвам итә. Бу теманы кузгату яңа фәнни ...ләргә юнәлеш бирә.

### Кулланылган әдәбият исемлеге


1. Гыйльманов Г. Язмышның туган көне / Татар балалар әдәбияты: Әкиятләр һәм ...ләр. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2003. – Б.368-412.
2. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов, В.Р.Әминева.– Казан: Мәгариф, 2005. – ... б.
3. Заһидуллина Д. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм ...чалык). – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.
4. Минһаҗева Л.И. XX гасыр татар балалар әдәбияты: үзенчәлекләре һәм үсеш тенденцияләре. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2011. – 312 б.


## XX гасыр татар шигъриятендә образ-символларның кулланылыш үзенчәлеге


***Н.М.Юсупова,***
*к.ф.н., доцент*
*Россия, Казань*


Татар әдәбиятында символлардан файдалануның бай тарихы, үзенчәлекле тәҗрибәсе бар. Теләсә кайсы милли әдәбияттагы кебек үк, татар поэзиясендә дә символларның тамырлары фольклор, халык авыз иҗаты әсәрләренә тоташа һәм буыннар, әдәби чорлар аша үтеп, мәгънәви яктан байый, төрлеләнә. Икенче яктан, милли җирлектә символларның активлашуына шәркый әдәбиятларның, әдәби-эстетик фикеренең йогынтысы көчле була.

XX йөз шигърияте дә бу яктан бай һәм төрле, бу дәвер сүз сәнгате символларны сыйфат һәм сан ягыннан тагын да тулыландыра, мәгънәви яссылыкта баета, киңәйтә. Көнчыгыш әдәбияты традицияләренә нигезләнеп үскән һәм XX йөз башында рус, аның аша көнбатыш әдәбиятлары йогынтысын тирән тойган милли сүз сәнгате XX гасыр әдәбиятында символларга яңача караш булдыра.

«Символлар үзләрендә бер-берсенә бәйләнгән һәм капма-каршы ике иҗади башлангычны берләштерә: бер яктан алар сүз сәнгатенең үткән гасырлар сынавын кичкән классик традицияләргә нигезләнүен чагылдырса, икенче яктан шул традицияләрне «үтеп китеп», аларны яңарту, трансформацияләү омтылышын раслый. Шуңа да символлар әдәбиятның тирән үзгәрешләр кичергән борылышлар вакытында, бер үсеш баскычыннан башка этапка күчү чорында, чиктәш ситуациягә аяк баскан вакытларда аеруча активлаша» [6, 207]. Л.А.Колобаеваның рус әдәбиятына мөнәсәбәтле әйтелгән әлеге фикере милли җирлектә дә актуаль яңгырый.

Узган гасыр татар поэзиясендә символлар активлашуның «беренче дулкыны» XX йөз башына туры килә. Милли сүз сәнгатендәге үзгәреш-яңарыш гасырлар дәвамында кулланылып килгән символларны сәнгати үзләштереп кенә калмый, аларны традицион булмаган мәгънәләргә дә баета. Шушы чорда күпкатламлы, киң эчтәлекле символлар борынгы мәҗүси, фольклор традицияләренең, Шәрык мәдәниятенең, рус һәм Европа